ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәр Думасы тарафыннан кертелгән «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 18 декабрендә 11 сәгать 30 минутка кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын кергән төзәтмәләрне исәпкә алып эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2280-VI ДС

ПРОЕКТ

«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

**1 статья**

Әлеге законның кушымтасы нигезендә Казан шәһәре районнарының чикләрен үзгәртергә.

**2 статья**


2015 елның 25 апрелендәге 30-ТРЗ номерлы «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Казан шәһәрендәге
районнар чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Казан шәһәрендәге районнар
чикләренең

**Карта-схемасы**



2) 2 нче кушымтада:

а) «Казан шәһәренең Вахитов районы чиген картографик тасвирлау» бүлегенең дүртенче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сара Садыйкова урамына кадәр» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр төньякка таба уза» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Казан шәһәренең Идел буе районы чиген картографик тасвирлау» бүлегенең беренче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр төньякка таба уза» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Казан шәһәре Совет районы чикләренең картография тасвирламасы» бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Совет районының басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге буенча уза.».

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Казан шәһәрендәге
районнар чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
Казан шәһәрендәге районнар чикләрен

**Карта-схемасы**



**«“Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«“Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проекты 2018 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең чикләре һәм аның статусы турында»гы һәм «“Питрәч муниципаль районы” һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль берәмлеге территорияләренең чикләрен билгеләү һәм аның статусы турында»гы Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 21 июлендәге 47-ТРЗ номерлы «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең чикләре һәм аның статусы турында»гы һәм «“Лаеш муниципаль районы” һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль берәмлеге территорияләренең чикләрен билгеләү һәм аның статусы турында»гы Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Законы, 2022 елның 4 октябрендәге 60-ТРЗ номерлы «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең чикләре һәм аның статусы турында»гы һәм «“Биектау муниципаль районы” һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр» муниципаль берәмлеге территорияләренең чикләрен билгеләү һәм аның статусы турында»гы Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Законы, «“Биектау муниципаль районы” һәм аның составына керә торган «“Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен үзгәртүнең беренче мәсьәләсе буенча, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Казан шәһәре районнарының чикләрен үзгәртүнең икенче мәсьәләсе буенча 2022 елның 20 гыйнварында узган ачык тыңлауларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнарының чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча 2022 елның 26 маенда узган ачык тыңлауларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 24 июлендәге ПР-182 номерлы йөкләмәсе нигезендә әзерләнде. Нәтиҗәдә Казан шәһәре районнары чикләренә үзгәрешләр кертү зарурлыгы барлыкка килде.

Закон проекты Казан шәһәре Совет районы чикләренә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урнашкан «Фәнни шәһәрчек» территорияләрен, Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урнашкан «Курган» җирләү комплексы территорияләрен, Казан шәһәре Идел буе районы чикләренә Казан шәһәре

муниципаль берәмлегендә урнашкан «Динамо» биатлон комплексы территорияләрен кертү, шулай ук Казан шәһәре Вахитов һәм Идел буе районнарының Нурсолтан Назарбаев урамы буйлап Вахитов мәйданына кадәрге чикләрен чагылдыруда техник хаталарны төзәтү максатыннан, Казан шәһәре районнары чикләрен үзгәртүне күздә тота.

Закон проекты Казан шәһәрендә чикләрнең тәкъдим ителә торган үзгәрешләре нигезендә район чикләренең карта-схемасын һәм картографик тасвирламасын яңа редакциядә бирү өлешендә үзгәреш кертүне күздә тота.

Карта-схемада Казан шәһәре муниципаль берәмлеге составына кертелгән территорияләр сурәтләнгән. Идел буе һәм Совет районнары чикләрен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең яңа ясалган чикләре нигезендә үзгәртергә тәкъдим ителә.

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2022 елның 20 гыйнварында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен һәм Казан шәһәре районнары чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча ачык тыңлаулар үткәрелде һәм 2022 елның 26 маенда Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрелде. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча халык Казан шәһәре районнары чикләрен үзгәртү турындагы инициативаны хуплады. Шулай итеп, законнарда каралган процедуралар үтәлде.

Казан шәһәре районнары чикләренең фаразланганча үзгәрүен исәпкә алып, Казан шәһәренең Совет районында халык саны якынча 600 кешегә артачак һәм якынча 340 мең кешене тәшкил итәчәк, Идел буе һәм Вахитов районнары халкы саны үзгәрмәячәк.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.

**«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә**
**гамәлдән чыккан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яки**
**кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм**
**башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын гамәлдән чыккан дип тануны, туктатуны, үзгәртүне яки кабул итүне таләп итмәячәк.

**«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс чаралары бүлеп бирүне таләп итми.